**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Об использовании беспилотных воздушных судов на территории Республики Татарстан

В целях усиления охраны общественного порядка, обеспечения общественной безопасности и безопасности объектов промышленности и транспортной инфраструктуры на территории Республики Татарстан, на основании пункта 5 Указа Президента Российской Федерации от 19 октября 2022 года № 757 «О мерах, осуществляемых в субъектах Российской Федерации в связи с Указом Президента Российской Федерации от 19 октября 2022 г. № 756» **постановляю**:

1. Запретить использование беспилотных воздушных судов на территории Республики Татарстан, за исключением беспилотных воздушных судов, используемых в установленном законодательством порядке органами государственной власти и подведомственными им организациями, органами местного самоуправления, иными организациями и физическими лицами по договору с органами государственной власти и подведомственными им организациями, органами местного самоуправления в рамках возложенных на них функций.

2. Установить, что мера, предусмотренная настоящим Указом, устанавливается на срок до снятия режима (уровня базовой готовности), введенного пунктом 5 Указа Президента Российской Федерации от 19 октября 2022 года № 757 «О мерах, осуществляемых в субъектах Российской Федерации в связи с Указом Президента Российской Федерации от 19 октября 2022 г. № 756».

3. Настоящий Указ вступает в силу со дня его официального опубликования.

АДМИНИСТРАЦИЯ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК

**Президент Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань, Кремль
25 ноября 2022 года
№ УП-813

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы территориясендә пилотсыз һава судноларын куллану турында**

Җәмәгать тәртибен саклауны көчәйтү, Татарстан Республикасы территориясендә иҗтимагый иминлекне, сәнәгать объектларының һәм транспорт инфраструктурасының куркынычсызлыгын тәэмин итү максатларында, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе Президентының 2022 елның 19 октябрендәге 756 номерлы Указы белән бәйле рәвештә Россия Федерациясе субъектларында башкарыла торган чаралар турында» Указының 5 пункты нигезендә **карар бирәм:**

1. Аларга йөкләнгән функцияләр кысаларында дәүләт хакимияте органнары һәм алар карамагындагы оешмалар, җирле үзидарә органнары тарафыннан, дәүләт хакимияте органнары һәм алар карамагындагы оешмалар, җирле үзидарә органнары белән килешү нигезендә башка оешмалар һәм физик затлар тарафыннан законнарда билгеләнгән тәртиптә файдаланыла торган пилотсыз һава судноларыннан тыш, Татарстан Республикасы территориясендә пилотсыз һава судноларын куллануны тыярга.

2. Әлеге Указ нигезендә күздә тотылган чара Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе Президентының 2022 елның 19 октябрендәге 756 номерлы Указы белән бәйле рәвештә Россия Федерациясе субъектларында башкарыла торган чаралар турында» 2022 елның 19 октябрендәге 757 номерлы Указының 5 пункты нигезендә кертелгән режим (база әзерлеге дәрәҗәсе) бетерелгәнгә кадәр кертелә.

3. Әлеге Указ рәсми бастырып чыгарылган көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** — **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ · АДМИНИСТРАЦИЯ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2022 ел, 25 ноябрь
№ ПУ-813